КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 27 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 27 окябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Түбән Уратма торак пунктындагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм кайтарту)

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 573 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 293 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 293 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

«Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге гражаннардан тыш, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү: Түбән Уратма торак пунктындагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм кайтарту)

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Уратма авыл җирлеге башлыгы А. Р. Гарифуллин